ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.02.2024 г. Заинск № 87

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 29 декабрендәге 3042 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж ташу Кагыйдәләрен раслау турында» карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 26 октябрендәге 1742 номерлы "Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану, Федераль Дәүләт транспорт күзәтчелеген, транспорт куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләр, шулай ук транспорт чараларын техник карау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнары актларының кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыгару турында" карарына ярашлы, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 29 декабрендәге 3042 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Юрист

Г.Х.Никифорова